**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 16.12.2020** **№ 945**

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 28 сентябрендәге 2103 номерлы «Биектау муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына торглар уздыру тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон, 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы «Реклама турында», 1995 елның 26 декабрендәге 208-ФЗ номерлы «Акционерлык җәмгыятьләре турында», 1998 елның 8 февралендәге 14-ФЗ номерлы «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында» Федераль законнар нигезендә, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 28 сентябрендәге 2103 номерлы «Биектау муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына торглар уздыру тәртибе турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карарның 2 пунктында (Р.Р.Хәсбиев) сүзен (С.М.Минһажев) сүзенә алыштырырга;

2) карарга 2 нче кушымтаның 8.2. пунктындагы 5 абзацта:

а) беренче җөмләдә «гариза бирүченең мөһере белән таныкланган» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

б) икенче җөмләдә «гариза бирүченең мөһере белән таныкланган» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә.;

3) карарга 3 нче кушымтаның 2 бүлегенең 2.1 пунктындагы 2.1.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.3. Биектау муниципаль районы башкарма комитеты реклама конструкциясенең техник торышы турында акт соратырга хокуклы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин